РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.10.2024 Буа шәһәре № 306 Бк/к

2025 елга Буа муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 елгы 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «Буа муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында»2007 елның 10 декабрендәге 360 номерлы карары нигезендә Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2025 елга кушымтада бирелә торганнарны расларга:

Буа муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнарны;

2. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ (А.Р. Әюповка) мәгариф оешмаларын әлеге карарның 1 пункты белән расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л. Н.Садретдиновага йөкләргә.

Җитәкче Л.Р. Шакирҗанов

Буа муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең
«29» нобрь 2024 № 306 Бк/к
карары белән расланды

Буа муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнар

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль урнашуы | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга сумнар |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җирлеге | 118316 |
| | авыл җирлеге | 119559 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | шәһәр җирлеге | 177385 |
| | авыл җирлеге | 181658 |